ИЛ ГОРУРЛЫГЫ

Президент «КАМАЗ-Мастер» командасын котлады

> 2

КАРЛЫ КЫШ

мул уңышка ишарәли

> 2

РӨСТӘМ УСМАНОВ:

«Бер елда 50 млн кубометр газны экономияләдек»

> 4

ТАТАРСТАНЛЫЛАР – ОЛИМПИАДАДА

Россия җыелма командасына бездән 8 спортчы керде

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 13 (28786) | Шимбә | 29 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ЧИР БАЛАЛАРГА КҮЧТЕ

Вазгыять

Иң кадерле җаннарны да аямый. Коронавирус инфекциясе балаларга да ныклап ябышты. Вазгыять ни дәрәҗәдә җитди? Белгечләр нинди киңәшләр бирә? Ата-аналарга нәрсә эшләргә? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауларга ачыклык кертергә тырышты.

«Бу кадәр күп бала килгәне юк иде әле!» Республиканың балалар клиник хастаханәсе хезмәткәрләре шулай дип чаң суга. Гыйнвар аенда кабул ителгән балалар саны, 2021 елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бермә-бер күбрәк.

Хастаханәнең баш табиб урынбасары Светлана Сенек сүзләренчә, узган ел белән чагыштырганда быел коронавирус белән чирләүче балалар күбрәк. Хәзер вакытлыча госпитальдә 80ләп бала дәвалана. Сырхау нәниләрне дә, үсмерләрне дә аяктан ега. Тумас борын госпитальгә эләгүчеләр дә юк түгел.

Педиатр, балалар пульмонологы Илнур Закиров әйтүенчә, хастаханәнең вакытлыча госпитале киеренкелек чигендә эшли. Интенсив терапия таләп ителгән сырхаулар да бар. Хроник чирләре булган балалар кислород ярдәмендә суларга мәҗбүр. Шулай да, бәхеткә, үпкәне ясалма җилләтү аппаратына тоташтырылган балалар юк. «Ике еллап эшлибез, әмма моның кадәр күп баланы кабул иткәнебез юк иде әле. Элеккеге штаммнар балаларны азмы-күпме урап узса, хәзер «омикрон» дулкыны аларны да чолгап алды», – ди белгеч.

Табиблар хәлнең шулай кискен торуын сөйләп торганда, ата-аналарга ниләр турында белеп тору кирәк соң?

Балалар һәм COVID. Белгечләр сүзләренчә, чир үзен ОРВИ кебек тота. Температура күтәрелә, аны берничек тә төшереп булмый. Бу, гадәттә, өч тәүлеккә сузыла. Моңа ларингит, бронхит, калтырану кебек билгеләр өстәлергә мөмкин. Әгәр бала авырый, бөтен симптомнары булып та, ул үзен гадәттәгечә тота (ашый, эчә, уйный) икән, хастаханәгә чабарга кирәкми. Күбесенең өч тәүлектән соң температурасы да төшә, хәле дә яхшыра.

Әгәр дә тән температурасы 38дән артыграк, балада беренче көннәрдә үк хәлсезлек, ашау-эчү теләге кимү, күңел болгану, эч китү, калтырану кебек билгеләр күзәтелсә, «ашыгыч ярдәм» чакырту зарур.

Чир кем өчен куркынычрак? Коронавирус артык авырлыгы булган балаларга аеруча куркыныч. Башка чирләре булганнар да вирус каршында көчсезрәк. ДЦП, йөрәгенә операция ясалган, трансплантация кичергәннәргә дә куркыныч яный.

Сан

- Татарстандагы гомуми вазгыятькә килгәндә, узган тәүлектә коронавирус белән чирләүчеләр саны **412**гә җиткән. Хәзерге вакытта чир таралу коэффициенты **100** мең кешегә **2,3** процентны тәшкил итә. Элек ул 100 мең кешегә **0,9–1** процент иде.
- **37** кешедә «омикрон» штаммын ачыклаганнар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бу атнада Татарстанда балаларга вакцина ясый башладылар. Ата-аналар икегә бүленде: нишләргә?

Казаннан Зәйнәп Харисова, медицинага ышанмасаң, өйдә генә утырып, беркая да чыкмый, берәү белән дә аралашмый торган тормыш рәвеше алып барырга гына калыр иде, ди. Балаларга вакцина уйлап табулары турында менә нинди фикердә ул:

– Мин вакцина ясатырга каршы түгел. Әлбәттә, балама 14 яшь кенә әле. Әмма, сәламәт икән, ник ясатмаска? Белгечләр аны юктан гына уйлап тапмагандыр. Берәр җирең авыртса, тизрәк табиб искә төшә. Теләсә кайсы вакцина яңа чагында куркыта. Шикләнгән кеше бар нәрсәдән дә шикләнәчәк ул. Бу – чир.

Татьяна Погодинаның да бу көннәрдә баласы өчен аеруча борчылган көннәре.

– 15 яшьлек балабыз авырып китте. Коронавирус икәнен әйттеләр. Бала авырганда бер генә ата-анага да җиңел түгелдер инде ул. «Нигә вакцина иртәрәк уйлап табылмаган икән?» – дим. Бәлки, җиңелрәк узган булыр иде, – ди ул. – Без гаиләдә барыбыз да: ирем дә, мин дә, олы балабыз да вакцина ясаттык. Чир йоктырган балабыз белән һәрдаим бергә булып та, инфекция безгә эләкмәде. Гомумән, чирнең әсәре дә юк.

Әлбәттә, шикләнгән ата-аналарның да хәлен аңларга була. Күпләрне «вакцина әле сынау фазасында гына» дигән сүзләр дә шүрләтә. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов әйтүенчә, вакциналар киң кулланылышка бары тик клиник тикшеренүләр тәмамлангач һәм I, II фазалар тәмамлангач кына керә. Хәзерге вакытта балалар өчен вакцинаны тикшерүнең III фазасы бара. «Бөтен вакыт дәвамында теләсә кайсы вакцинаны куллану барышын күзәтү дәвам итә. Гомумән, бу бит теләсә кайсы даруга кагыла», – дип аңлатты белгеч.

Шулай да ике золым арасыннан берсен сайларга туры килсә, вакцина турында уйланырга киңәш итә белгечләр, чөнки чир бала организмына яман үзгәрешләр алып килергә мөмкин.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының йогышлы авырулар буенча штаттан тыш балалар белгече Владимир Анохин сүзләренчә, чир йоктырган балаларның күпчелегендә эчәклеккә бәйле проблемалар очрарга мөмкин. Балалардагы коронавирусның бер билгесе итеп эч китүне дә атарга була. Аның каравы сулыш органнарының зарарлануы сирәк очрый, очраса да, күбрәк үсмерләрдә күзәтелә.

Ахыры 2 нче биттә >

Хосусый клиникаларга – дәүләт акчасы

Ил хөкүмәте 65 яшьтән өлкәнрәкләрне озак вакыт карау өчен хосусый медицина оешмаларына 351 миллион сум бирәчәк. Андый клиникаларны өлкәннәргә булышуга җәлеп итү буенча пилот проекты 2020 елда башланды. Анда 15 төбәк, шул исәптән Татарстан катнаша. Республика бу максатка 8,4 миллион сум алачак. Федераль ярдәм илдә 3,7 миллион ялгыз әби-бабайны карау мөмкинлеге бирәчәк.

Әлеге тәҗрибәдә катнашучы төбәкләрдә шәхси клиникалар өлкәннәр беркетелгән сырхауханә белән берлектә эшләп, аларга участок табибы билгеләгән ярдәмне күрсәтә. Мәсәлән, аларның белгечләре өйгә килеп, өлкәннәргә даими медицина тикшерүләре уздырырга, анализлар алырга мөмкин. Проектта катнашу өчен оешмалар конкурс нигезендә сайлап алына. Конкурс нәтиҗәләре буенча аларга грантлар бирелә.

Эш җайланган

Ел башыннан Татарстанда 120 мең чамасы электрон «больничный» бирелгән инде. Социаль иминиятләштерү фондының төбәк бүлеге белгече Аида Волкова әйтүенчә, 1 гыйнвардан вакытлыча эшкә яраксызлык буенча электрон документка тулысынча, бернинди кыенлыкларсыз күчелгән. Узган ел да әлеге медицина документының 0,5 проценты гына кәгазьдә рәсмиләштерелгән. Гомумән алганда, 2021 елда барлыгы 1,4 миллионнан артыграк электрон «больничный» бирелгән. Волкова әйтүенчә, кешеләр өчен дә, медицина оешмалары өчен дә уңайлы бу.

Авылларга – сыйфатлы интернет

Быел Татарстанда халык саны 100дән 500 кешегә кадәр булган 61 авылга 4G-интернет (югары тизлекле мобиль интернет) кертеләчәк. Узган елда 305 авыл халкы үзләренең смартфонында сыйфатлы интернетка тиенгән. Бу хакта Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр итә. Гомумән алганда, илдә 2030 елга кадәр «Цифрлы икътисад» илкүләм программасы буенча 24 меңләп кечкенә авыл шундый элемтә белән тәэмин ителергә тиеш. Быел ул Россиянең 2002 авылында пәйда булачак.

Республикада 3087 авылның 1335ендә 3G һәм 4G элемтә юк. Бу – чама белән 200 мең кеше, ягъни төбәктәге халыкның 5,5 проценты рәтле-башлы интернеттан файдалана алмый дигән сүз.

Яңалык

Февраль үзгәрешләре

Ана капиталын инфляциягә карап арттыру, бурычлыларның минималь керемен тотып калмау, авария хәлендәге торак турында мәгълүматларны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына (ЕГРН) кертү турында законнар үз көченә керә.

АНА КАПИТАЛЫ. Февральдән башлап, ана капиталы, фараздагы түгел, ә чынбарлыктагы инфляция күләменә карап арттырылачак. Анда калган акча да шул тәртиптә исәпләнелә. Исегезгә төшерәбез: узган елда ана капиталы беренче балага – 483881 сум, икенчесенә – 639431 сум тәшкил итте. 2022 елда, 8,4 процентка артып, 524,5 мең сум һәм 693,1 мең сум булачак.

БАШКАРУ ПРОИЗВОДСТВОСЫ. 1 февральдән «Башкару производствосы турында»гы Законның яңа нигезләмәләре үз көченә керә. Аның буенча, бурычлы кешенең акчасы кырып-себереп тотып калынмый. Закон нигезендә, бурычлы суд приставларына яшәү минимумыннан ким булмаган күләмдә айлык керемен саклап калу турында гариза белән мөрәҗәгать итә ала. Шул ук вакытта ул әҗәтен түләтүчеләргә керем чыганаклары һәм банктагы счет номеры турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш.

Закон проекты тормышта авыр хәлдә калучыларны яклауга юнәлдерелгән. Ләкин бу яңалык алимент түләү, сәламәтлеккә китерелгән зыянны, җинаять кылу сәбәпле китерелгән зыянны каплау буенча бурычларга кагылмый.

ТОРАК. Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры өземтәсендә торакның нинди хәлдә булуы күрсәтелә башлаячак. Яңа закон нигезендә, аңа торакның авария хәлендә, яшәү өчен яраксыз булуы, яңартылырга яки сүтелергә тиешлеге турында мәгълүматлар кертеләчәк. Тиешле органнар 1 июльгә кадәр Росреестрга моңа кадәр «авария хәлендә» дип танылган күпфатирлы йортлар турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш.

ЭКОЛОГИЯ. Әйләнә-тирә мохитне саклауга салкын караучы предприятиеләргә штраф күләме арта. Әйтик,

Илдар Мөхәммәтҗанов

һавага зарарлы матдәләр чыгаруны автомат күзәтү системасын урнаштырмаган өчен вазыйфаи затлар – 20–40, юридик затлар 100–200 мең сум штраф түләячәк. Моңа кадәр аның күләме 20 мең сумга кадәр генә булган.

ИМИНЛЕК. Гадәттән тыш хәлләрнең (табигать афәте яки техноген һәлакәт) янавы игълан ителгәннән соң кешеләрнең эвакуацияләнергә тиешлеге турында закон үз көченә керә. Бу законны яңарту, шул исәптән хәбәр салуның яңа техник чаралары пәйда булуга бәйле. Эвакуация, элеккечә үк, кешеләрнең тормышы куркыныч астында калганда гына башкарылачак. Шул ук вакытта яңа законда аннан баш тартучыларга җаваплылык каралган: афәт янаса да, йортын ташлап китәргә теләмәүчеләр 1–30 мең сумлык штрафка тартылачак.

Сүзгә-сүз

Ринат САДЫЙКОВ, яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары:

Безнең өчен мөһим бурыч – яшьләрне авылда калдыру. Бу – безнең «баш авыртуы». Бөгелмә, Лениногорск, Әлмәттән соңгы өч елда гына да яшьләрнең 60 проценттан артыгы киткән. Бу әле – зур шәһәрләргә укырга дип киткән һәм кайтмаячак студентлар гына.

(Дәүләт Советының Социаль сәясәт буенча комитеты утырышында чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – ТОРМЫШКА МӨНӘСӘБӘТ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге Россиядә яшәүчеләрнең көндәлек тормышны нәрсәсез күз алдына китермәвен белешкән.

Эш	31%
Туганнар һәм якын кешеләр	15%
Телефон һәм башка гаджетлар	13%
Азык-төлек	10%
Балалар һәм оныклар	9%
Транспорт	9%

Сак булыгыз!

Синоптиклар фаразлавынча, республикада 31 гыйнвар һәм 1 февральдә һава температурасы +1гә кадәр җылынып, җепшек кар явачак. Соңгы вакытларда кар күп булды. Җепшеткәч, кар һәм боз кантарлары түбәдән җиргә төшеп, кешеләргә зыян салырга мөмкин. Шуны истә тотып, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе белгечләре урамнарда игътибарлы һәм сак булырга, йортлар тирәсеннән читләтебрәк узарга, машиналарны йортлар янәшәсенә куймаска киңәш итә. Баш идарә җитәкчесе Рафис Хәбибуллин районнар хакимиятләре башлыкларына кар һәм боз төшү ихтималы булган урыннарны ачыкларга, әлеге куркыныч турында халыкка аңлату эшләре алып барырга, шулай ук юлларны, түбәләрне чистарту буенча коммуналь хезмәтләр эшен оештырырга киңәш иткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Кыйммәтләр очсызланмасын дип

Россия Мәдәният министрлыгы «Традицион кыйммәтләрне саклау һәм ныгыту» дигән план-проект хәстәрләде. Анда илдә яшәүче халык алдына килеп басарга мөмкин рухи-әхлакый үсеш киртәләре, безне «бозарга» мөмкин чит-ят идеяләр исемлеге китерелгән. Һәм, әлбәттә инде, Россия өчен һәрчак зарур саналган, милли дип табылган төп кыйммәтләр санап чыгылган. Проект-программа буенча фикер алышу, аны тулыландыру өчен вакыт алай ук күп каралмаган: 4 февраль җитүгә, документ расланыр дип көтелә.

Россияле халык сакларга, кыйбла итәргә тиешле традицион нормалар нинди соң? Буыннан буынга күчеп барырга тиешле милли ориентирлар дип министрлык кешегә, аның гомеренә ихтирам-хөрмәт, хокук һәм ирекләр, ватанпәрвәрлек, ватанга хезмәт итү, югары әхлакый идеаллар, ныклы гаилә, рухи байлыкның матди байлыктан өстенлеге, тарихи хәтер, кешелеклелек, шәфкатьлелек, гаделлек һ.б. саный. Табигый ки, саналганнарның күбесе гомумкешелек кыйммәтләре булып, үтәлгән очракта алар, дәүләтенә, яшәү урынына карамастан, һәр җәмгыятьне бизи. Илебез, биредә яшәүче халык ул асыл сыйфатларны тоташ үз итә, ныгыта, саклый алырмы, андый бизәлеш тормышыбызны яхшыртып, проблемаларны киметерме? Сораулар әлегә җавапсыз.

Министрлыкның гамәле, борчылуы аңлашыла. Илдәге рухият торышы булсын, дөньядагы рухи климат, кешене – кеше, халыкны халык итәргә тиеш кыйммәтләр булсын – алар бүген һич тә кирәкле югарылыкта түгел. Бүгенге процессларга карап, алар яхшырыр, дип әйтү дә авыр. Белергә теләгән белә булыр – әле бер гасыр элек кенә гаиләгә, дингә, никахка, тәрбиягә мөнәсәбәт бөтенләй башка булган. Анда тирәнлек һәм җитдилек өстенлек иткән. Бүген гаилә институты, диннәр, тәрбия алымнары – барысы да кризиста. Без күп нәрсәләргә артык җиңел һәм җавапсыз карарга өйрәндек. Җиһан белән гламур, кыланчыклык, ялтырау, барыннан да бигрәк акча идарә итә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә күбек күбәйде. Бушлык, сансызлык артты. Чынлык, тирәнлеккә кытлык барлыкка килде. Дөнья, дөресен әйтик, шактый бозык һәм җилбәзәк бүген.

Россиядәге хәлләр дә шактый катлаулы. Безнең ил дигәндә, проблеманы биредә башкачарак аңлау да бар кебек. Төрле идеолог, сәясәтчеләр әйткәннәрдә генә түгел, проекттагы аерым җөмләләрдән дә биредәге халыкны, Көнбатыштан, андагы күпсанлы милләтләрдән өстен санау, иманлырак, әхлаклырак, хәтта ки затлырак итеп күрергә теләү дә сизелә. Рухият торышы өчен җаваплы аерым затларның биредә традицион саналган «ырмау»лар (скрепы) – ватан, аңа бирелгәнлек, байлыктан бигрәк рухияткә тартылуны (духовность), гаиләгә игътибар, төрле «зәңгәр», «ал»лыкка кискен негатив караш, башкаларны – югары сортлылыгыбыз, безне коткарачак фактор, дип бәяләве бер бүген генә түгел. Бу дөресме? Көнбатыштан, шул ук Европадан йөз чөереп кенә өстен була алырбызмы? Күңелгә хуш килмәгәннәре булган кебек, алардан алыр, өйрәнер сыйфатлар да юк түгел бит. Һәм киресенчә, бездә дә үзебез күркәмгә чыгарган, тик калганнар һичкайчан кабул итмәячәк яклар да бар. Гомумән дә, Шпенглер дигән автор үзенең «Закат Европы» дигән китабын язганнан бирле – гасыр буе «Иске дөнья»ны кайберәүләр югалып, инде бетеп баручы цивилизациягә чыгарып килсә дә, гомумкешелек кыйммәтләре ул кыйтгада үтәлми, дию хата булыр иде. Тормыш дәрәҗәсе, сыйфаты хакында бөтенләй дә искәртәсе түгелдер.

Безләрдәге бик үк күркәм булмаган сыйфатлар дигәннән, мәгълүм тележурналист һәм җәмәгать эшлеклесе Дмитрий Губин дигән кешенең үзенчәлекле фикеренә игътибар итик. «Бөек халык, кабатланмас рухият (духовность), традицион кыйммәтләр – мин килешкән гыйбарәләр түгел. Мин россияле кавемне яратмыйм. Нигә дисезме? Теләсә кайсы хаким умырткасыз ул массаны үзе теләгән якка бөккәнгә. Илдәге халыктан теләсә нәрсә әвәли алганга яратмыйм. Россияле халык пластилин кебек…» Журналист күз уңында тоткан юашлык, буйсынучанлык, артык басынкылык ише сыйфатлар, алардан арыныйк, дию, әлбәттә инде, иселе телгә алынган проектта юк. Тик анда тагын бер хакыйкать бар кебек. Бар булган гаделсезлекләрдә властьны гаепләү дөрес түгел. Бездәге власть та Марстан килмәгән, шушыннан чыккан. «Һәр халык үз хөкүмәтенә лаек» («Каждый народ имеет такое правительство, какое заслуживает») – миңа калса, даһи билгеләмә. Барысы да халыкка, аның сыйфатына, үзаңга бәйле. Әлеге хәл татарга да бик кагыла. Әбиләргә әллә оныклары белән вата-җимерә русча сөйләшергә Мәскәү яисә Татарстан хөкүмәте кушамы? Татар мәктәпләрендә физика, математика, химияне русча укытыгыз, дип ата-аналар түгел, власть чәчрәп чыгамы?..

Министрлыкның план-проектындагы аерым пунктларга игътибар итик. «Ул пунктлар үтәлер шартлар бармы, тудырылганмы?» дигән сорау куйыйк. Хокук һәм ирекләр. «Тирәнтен халык» аларсыз да ярала, яши ала, әлбәттә. Тик традицион саналган кыйммәтләрне саклап яхшырудан тыш, искәртүебезчә, «халык сыйфаты» дигән киңрәк һәм гадирәк төшенчә дә бар бит әле. Сыйфатлы халык ул – ни дисәң дә, басынкы, «алма, пеш, авызыма төш», дип торган, хакимнәр игелегенә исәп тоткан кешеләр төркеме түгел, ә актив гражданлык позициясе булган, хокуклары өчен көрәшә белгән халык. Хөрлек юк икән, сыйфат та була алмый. Бу да – кагыйдә.

«Рухи байлыкларның матди байлыктан өстенлеге». Матур, яңгырашлы пункт. Бар халык та таза тормышта яшәгәндә ул күпмедер үтәлер дә иде. Тик байлар белән ярлылар арасындагы упкын тирәнәеп торганда гади кешегә: «Син кичке ашыңны ашама, китап укы», – дип әйтү авыр. «Форбс» исемлеге уңышлылык үлчәгече саналып, кешелек гасырлар буе чишә алмаган мәсьәләне чишкән математик Григорий Перельман үзенә тиешле миллион доллардан баш тарткан өчен диванага чыгарылганда рухи байлык өстенлеге хакында сүз куертып була микән?..

Булган кыйммәтләрне саклау, рухияткә йөз белән борылу, аңа өстенлек бирү – дөньяви проблема. Аларны күмәкләшеп хәл итәргә алынасы иде. Миңа калса, ул максатка иң туры юл барыннан да бигрәк программада әйтелгән ирек-хөрлек, хокуклар аша ята. Ел саен дистәләгән проект, программа хәстәрләсәң дә, хөрлек юк икән, гавам үзгәрми. Ул теләсә кайсы хакимияткә түзә, аның яклы булып кылана. Хакимият гамәлләрен һава торышы кебек котылгысыз санаган халык, кыйммәтләр, дип күпме генә сөйләнсә дә, кыйммәтен арттыра алмыйдыр.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Сезнең җиңү – безнең өчен шатлык

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә «КАМАЗ-мастер» командасын «Дакар – 2022» ралли-марафонында чираттагы җиңүе белән котлады. Ул 19 нчы тапкыр җиңүнең нигезендә гаять зур осталык, ихтыяр көче ята дигән фикердә.

– Согуд Гарәбстаны чүлләре аша салынган ралли маршруты ярышларда катнашучыларның һәммәсе өчен зур сынауга әйләнде, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Шуңа да карамастан, бөтен команда әгъзаларының бик зур тырышлыгы белән иң зур нәтиҗәгә ирешелде: йөк машиналары буенча беренче дүрт урынны Татарстан командасы яулады.

Президент шулай ук, бүген «КАМАЗ» – бөтен дөньяга танылган Татарстан бренды, дип билгеләп үтте.

– Без барыбыз да сезнең өчен җан атып, уңышларыгызны игътибар белән күзәтеп бардык, – дип тәэсирләре белән уртаклашты Рөстәм Миңнеханов. – Сез безне Дакарда җиңүегезгә өйрәттегез, шуңа да сезнең беренчелекне яулавыгызга шикләнмәдек. Әлеге гаять катлаулы ярышларда экипаж әгъзаларының, техник персоналның зур осталыгы, мөмкинлекләр чигендә эшләү чираттагы уңышка китерде.

Президент команда әгъзаларына, автозавод җитәкчелегенә, республика Автомобиль спорты федерациясенә һәм команда иганәчеләренә рәхмәт белдерде. Җанатарларга, спортчыларның якыннарына аеруча җылы рәхмәт сүзләрен ирештерде. «Бүгенге катлаулы шартларда сезнең җиңү – Татарстанда яшәүчеләрнең һәркайсы өчен зур шатлык!» – диде ул, «КАМАЗ-мастер» спортчыларына мөрәҗәгать итеп.

«КАМАЗ-мастер» командасы автоспорт белән шөгыльләнүче яшьләргә үрнәк булып тора, бөтен дөнья күләмендә Татарстан һәм Россияне данлый», – диде Рөстәм Миңнеханов

ӨЙДӘГЕ МӘКТӘП

Республикада салкын тию авырулары таралуга юл куелмасын өчен, 7 мәктәп һәм 214 уку йортындагы сыйныфлар өйдә укуга күчкән. Әлегә бер атнага. Тик әти-әниләр, тагын үзебезгә укытырга калмагае, дип борчыла башлады инде.

Республикада көн саен 466 меңнән артык укучы һәм 32 меңгә якын укытучы иртәнге медицина тикшерүе уза. Кичә аны 751 бала үтә алмаган. Яңа уку елыннан андыйларның саны – 37671. Минзәлә, Лаеш, Зәй, Чирмешән районнарындагы җиде мәктәп вакытлыча ябылган.

Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Әсәдуллина әйтүенчә, балалар арасында авыру очраклары арта, әмма мәктәпләрне тулысынча дистантка күчерергә җыенмыйлар. Авыру җәелмәсен өчен, 1419 сыйныфны өйләренә таратып торырга туры килгән. Бу сыйныфлар арасында аз комплектлылары да, утыз укучылылары да бар.

– Әти-әниләр аңлап кабул итә. Алар үзләре дә мәктәпләрне дистантка күчерүне теләмиләр. Мәктәптә күп кеше катнашында чаралар, җыелышлар үткәрелми, алар бары сыйныфта гына оештырыла. Бактерицид лампалар бар, сыйныфлар җилләтелә. Шимбә көнне спорт чаралары ачык һавада узачак. Бу вакытта сыйныфлар яхшылап җыештырылачак һәм җилләтеләчәк, – диде Алсу Әсәдуллина.

Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов белдергәнчә, мәктәпләрне БДИ нәтиҗәләренә карап чагыштырырга ярамаган кебек, дистант формасын бары эпидемиологик вазгыятькә карап кына кертергә мөмкин. Хәзер «омикрон»га бәйле авырулар саны арта, балалар сәламәтлеген саклау өчен шундый чаралар кулланырга туры килә. Авыру чигенгәч, кабат традицион режимга кайтачаклар.

Мәктәпләргә шалтыратып, районнардагы вазгыятьне белештек.

– Өч сыйныф ябылды. Күпләп чирләүчеләр юк. Дистант кирәкми. Укытучыга да, әти-әнигә дә кирәк түгел ул. Бала мәктәптә белем алырга тиеш, – ди Тукай районы мәгариф бүлеге башлыгы Әлфәт Сабиров.

Баулы районының Исергәп мәктәбендә авыручы балалар юк икән, дистантка күчмәгәннәр. Минзәлә районының Тауасты Байлар мәктәбе дә укытуын дәвам итә. Анда бер-ике бала гына авырый.

Балалары өйдә укыган әти-әниләр генә шат түгел. Ни өчен дигәндә, эштә вакытта ул-кызларына биремнәр эшләргә булышырга кирәк. Эштән кайткач, өй эшләре көтә.

– Улларыбыз 83 нче лицейда белем ала. Олы улыбыз Эмиль мәктәпкә йөри. 1 нче сыйныфта укучы Диас сыйныфын бер атнага карантинга яптылар. Дистантның бер уңай ягын да күрмим. Балалар өйдә утыра. Ярый әле дәү әниләре бар. Биремнәрне аңламый. Көн буе тынгылык юк. Ачу чыгып бетә кайчак. Өй эшен дә бик күп бирәләр. Декрет ялындагы әниләр, көн буе утырабыз, диләр. Болай укулар озакка сузылмасын иде инде. Мәктәпкә баруны түземсезлек белән көтәбез, – ди Казанда яшәүче Эльвира Шакирова.

Лилия Гайнуллинаның бер кызы бакчага йөрсә, икенчесе 2 нче сыйныфта укый.

– Без «зум» аша укыйбыз. Шигырьне өйрәнеп, укытучыга видео төшереп җибәрергә кирәк. Инша язу авыррак, шуңа күрә кызыбыз яза алмады. Әти-әниләрнең күбесе – эштә, өйдә утыру мөмкинлеге юк. Кичке сәгать 6га кадәр өй эшен тапшырып бетерәсе. Берничек тә өлгереп булмый. Вундеркиндлар эшли инде аны, уртача укыганнарга җиңел түгел. Балалар чирләмичә, мәктәптә генә укый күрсеннәр. Өйдә уку – уку түгел, – ди Лилия Гайнуллина.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы әти-әниләрне тагын бер кат искәртә: «Авыру сәбәпле дәресләрдән азат ителгән балалар бер-берсе белән аралашмасын, җәмәгать урыннарына бармасын иде».

Сәрия МИФТАХОВА

Дәүләт Советында

Битарафлар булмаска тиеш

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин парламентның экспертлар советлары һәм профильле комитетлар җитәкчеләре белән очрашты. Законнар иҗат итү эшчәнлегенең ачыклыгын һәм нәтиҗәсен яхшырту, аларның тормышта кулланылышына җитди анализ ясау бурычларын куйды Фәрит Мөхәммәтшин.

Экспертлар советлары Дәүләт Советының барлык сигез комитеты каршында оештырылган. Аларның составына дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, иҗтимагый оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре керә. Советлар киңәшмә органы булып тора һәм җәмәгать башлангычында эшли.

«Без экспертлар эшен югары бәялибез. Сезнең бәя закон проектының «сәламәт бала булып тууы» өчен кирәк», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Законны төрле яклап тикшерүдән тыш, сайлаучыларга һәм халыкка аның ни өчен кирәклеген аңлату да бик мөһим, дип искәртте.

– Без сездән җентеклерәк анализ, республикада һәм илдәге социаль-икътисади процессларны фәнни бәяләвегезне көтәбез, – диде экспертларга парламент башлыгы. – Моннан тыш республика һәм федераль дәрәҗәдәге фәнни оешмалар, фондлар, консультатив советлар белән нәтиҗәле хезмәттәшлекне җайга салырга кирәк. Бүген Татарстанда 6 меңгә якын иҗтимагый оешма теркәлгән.

Россия Конституциясенә үзгәрешләр кертелү һәм гавами хакимият турында закон кабул ителү сәбәпле, якын киләчәктә республика законнарын үзгәртү буенча зур эш башкарырга туры киләчәк. Хәзерге вакытта Дәүләт Думасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында закон проекты карала. «Җирле үзидарә, кешеләргә иң якын торучы хакимият буларак, нәтиҗәле эшләргә тиеш, – диде Дәүләт Советы Рәисе. – Җәмгыятьтә әлеге закон проектына карата сораулар күп, без дә үз тәкъдимнәребезне әзерлибез».

Әлеге закон проекты җәһәтеннән кайбер экспертлар да үзләренең борчылуын белдерде.

– Күчеш чоры 2028 елга кадәр күздә тотылса да, җәмгыятьне нык борчый торган мәсьәлә бу, – диде Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитеты каршындагы Экспертлар советы рәисе Валентина Липужина. – Миңа калса, республикада бик зур авырлык белән булдырылган җирле үзидарә нәтиҗәле эшли, халык алдында абруйлы. Федераль закон проекты беренче укылышта кабул ителде. Экспертлар советының якын араларда узачак утырышларында барлык тәкъдимнәрне карарга ниятлибез.

Март аенда Казанда Идел буе федераль округы төбәкләренең дәүләт хакимияте законнар чыгару органнары ассоциациясе утырышын уздыру күздә тотыла. Анда калдыклар белән эш итү өлкәсендә реформаларны законнарга салу мәсьәләсе каралачак. Фәрит Мөхәммәтшин экспертлар советлары әгъзаларын әлеге мәсьәлә буенча фикер алышуга кушылырга чакырды. «Сезнең арада битарафлар булмаска тиеш», – диде ул һәм кискен мәсьәләләр буенча «түгәрәк өстәл»ләр үткәрү эшен көчәйтергә өндәде.

Чир балаларга көчте

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Табиб сүзләренчә, нейроковид (баш мие структурасына һәм аның йокы, кәеф, борчылу дәрәҗәсе өчен җавап бирә торган төрле бүлекләренә зыян килүе. – **Ред**.) дигән күренеш балалар өчен дә куркыныч.

– Зурлар өчен бу үзгәрешләр тормыш сыйфатына да тәэсир итә. Балалар организмы барыбер дә тиз яраклаша, социальләшә торган шул. Аларда хәтер начараю күзәтелергә мөмкин. Күпләп булмаса да, андый үзгәрешләргә юлыккан булды, – ди Владимир Анохин.

Чирнең көтелмәгән «күчтәнәч»ләреннән саклану өчен, балаларга һәм үсмерләргә вакцина ясату кирәк, дип саный белгеч. Педиатр Илнур Закировның да фикере шундый ук.

– «Спутник М» вакцинасының нәтиҗәлелеге бар, ул авырмаска булыша һәм күмәк иммунитет булдыра. Вакцина ясатканнан соң бала чир таратмый, шулай ук вакцинадан да чир ияртеп булмый. Аутоиммун чирләр прививка кадатмаска сәбәп булып тора. «Спутник М» инструкциясендә үк калкансыман биз, бавыр, бөер авырулары турында сүз бар. Теләсә кайсы вакцинация алдыннан бер кагыйдә үтәлергә тиеш: бала сәламәт булсын. Шуңа күрә дә табиблар аларны башта тикшерә. Сәламәтлек ул – баш авыртмау һәм температура булмау гына түгел әле. Бу – рухи һәм психик халәтебезнең тулы иминлеге дә, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ХАЛЫК СИНОПТИГЫ:
«КАРЛЫ КЫШ МУЛ УҢЫШКА ИШАРӘЛИ»

Авыл хуҗалыгы

Быелгы кыш кары белән сөендерә. Кар күп явып, шәһәр халкы өчен өстәмә мәшәкатьләр тудырса да, игенчеләр өчен куанычлы күренеш кенә. Чөнки карның күп булуы уҗымнар өчен яхшы.

– Әлегә быелгы кышка тел-теш тидереп булмый, – ди Кукмара районының баш агрономы Илдар Габбасов. – Кар да урыны-урыны белән яхшы ятты. Калын җире дә, кар азрак яуган җире дә бар. 30–60 см тирәсе. Әлегә көзге культураларның да торышы яхшы. Дөрес, бу вакытта яхшы була әле алар. Менә язны ничек чыгарлар, шуннан күп нәрсә тора. Бу чорда уҗымнар өстен боз капласа, яки культуралар көзен ачык калса, куркыныч була. Бер чорда боз каплап, куркытып алган иде. Анысы купшакланып, узып китте үзе тагын. Көзге культуралардагы шикәр күләме дә начар түгел.

Татарстан территориясе зур, шуңа күрә бер райондагы вазгыять икенчесенә туры да килеп бетмәскә мөмкин. Чүпрәле районының Иске Чокалы авылында яшәүче агроном Илдар Усманов әнә шулай ди.

– Безнең якларда кар яхшы ятты: 40–45 см булган урыннар да бар. Бу атна ахырында тагын кар көтәбез. Без инде яуган карга сөенеп кенә торабыз, чөнки файдасы бар. Кыш көне яңгыр түгел, кар яусын инде ул, – ди агроном. – Декабрь башларында яңгыр явып куркыткан иде бит. Ул боз эреп бетте үзе.

kukmor-rt.ru

Билгеле булганча, узган ел җәй дә, көз дә коры килде. Шунлыктан күп кенә районнар көзге чәчүне башламыйча тордылар. Чүпрәле районында да соңрак керешкәннәр иде. «Уҗымнар яхшы тишелде. Анысы күңелдә өмет уятты», – ди Илдар Усманов.

Белгеч әйтүенчә, соңгы елларда һава торышына бәйле халык сынамышлары дөреслеккә туры килми башлаган.

Районнардагы агрономнар сүзләрен «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» ФДБУның Татарстан буенча филиалы җитәкчесе урынбасары Любовь Занина да куәтли. Оешма белгечләре шушы көннәрдә, республика кырларына чыгып, уҗымнарның торышын анализлаган. 2,4 мең гектар мәйдандагы көзге культураларны сайлап алып тикшергәннәр.

– Фитомониторинг нәтиҗәләре буенча әзерләнгән мәгълүматтан күренгәнчә, республикада бер атна эчендә 25 мм кар яуган. Бу – айлык норманың яртысы, – ди Любовь Занина.

Кырларга чыгып тикшергән белгечләр көзге культуралардагы шикәр микъдарының 26–33 процент булуын билгеләгән.

– Бу – яхшы күрсәткеч, – ди алар. – Тикшерелгән кырларда көзге культураларның торышы яхшы һәм канәгатьләнерлек дип бәяләнде.

Бүгенге хәл яхшы булса да, белгечләр аграрийларга кырларны һәрдаим тикшереп торырга киңәш итә. Бу чәчүлекләрдә үсемлекләрнең яшәешен, тискәре факторлар белән зарарлану дәрәҗәсен вакытында ачыкларга һәм үсемлекләрне караугa җентекләп әзерләнергә мөмкинлек бирәчәк.

Халык синоптигы, Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче Рәис абый Шәкүров та, кар күп булуны бары тик яхшыга гына юрарга кирәк, ди.

– Кар бик күп быел. Бик шәп инде ул. Мин сезгә көз көне үк, кышын кар күп явачак, көннәр бик салкын булмаячак, дип әйткән идем. Быел бөтен нәрсә мул уңыш бирергә тиеш. Икмәге дә, бәрәңгесе дә, башка яшелчәләре дә. Бай ел булырга охшап тора. Уҗымнарга да кар шәп ятты. Басудагы кар атның корсак астыннан тора, – диде халык синоптигы.

Аның сүзләренчә, июль яңгырлы, салкынча булачак. Ләкин авыл хуҗалыгы өчен моны яхшыга гына юрарга кирәк, ди. Рәис абыйның юраулары юш килә торган иде, бу юлы да шулай булыр, дип өметләник.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

ПОРТ-АРТУР ДИГӘН КАЛАГА...

Узган гасырның җитмешенче елларында Яңа Рәҗәптә (хәзер Чәчәкле) «Порт-Артур»ны көйләп йөргәннәрен хәтерлим. Күршедә генә яшәгән Рәфыйк абый Хафизов та (урыны оҗмахта булсын) машина йөрткәндә бу җырны яратып җырлый иде. Авылдашларым ни өчен моңсу бу җырны үз иткән соң?

Беркөнне миннән олырак булган Илгизәр Хәйдәровтан шул хакта сораштырып тордым. Шактый ук кызыклы нәрсәләр турында сөйләде ул. 1904 елның 9 февралендә кабынып киткән рус-япон сугышында безнең авылдан да берничә кеше катнашкан. Мисал өчен, Рәфыйк абыйның әтисе Хафиз бабай, минем бабам Хәйдәр Мөхәммәтҗанов та шул сугышта булып кайткан. Дөрес булса, авылдан ким дигәндә унлап кеше шул сугышта катнашкан, дип сөйлиләр. Бабай да шул санны әйтә торган иде. Бу сугыш турында ул бик ачылып китеп сөйләргә яратмады. Шулай да кәефе булганда берничә эпизодны хәтерендә яңартып ала торган иде. Кызыксынып сорый башласам, үзәгенә үткәнгәдер инде, сүзен гел икенчегә борып җибәрде. Әйе, сугыш – уен түгел. Кемнең инде күрә торып ут эченә барып керәсе килсен? Шөкер, ашый торган ризыклары көткәнгәдер инде, Хафиз бабай белән Хәйдәр бабам япон сугышыннан яралансалар да, үз аяклары белән, исән килеш кайтканнар. Бабайның маңгае тегелгән иде, япон ядрәсе керде, өшетмичә-нитмичә генә акыртып тартып алдылар, дип сөйләде. Сугышта кыю, бик гаярь булган ул. Юкка гына IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләмәгәннәрдер! Солдат бүләген кульяулыкка төреп, Коръән китабы белән бер урында саклады. Шуны ялтырап торган дәрәҗәгә җиткәнче чистартып куя иде.

Хәйдәр бабайның «Каенлык» артында имана җире булган. Шуны эшкәртеп, бодай иккән. Шунысы гаҗәп: бабайга кайдан килгән бу җир? Рус-япон сугышында катнашкан өчен бирмәгәннәрме икән? Ул елларда бит авыл крестьяннары җирле булу турында хыяллана да алмаган. Шул кырдан җыеп алган бодайны эшкәртү өчен, бабай ызандаш Ульян өлкәсенең Кологреевка авылындагы танышларыннан, ат арбасына салып, сортларга аеру җайланмасы алып кайта торган булган. Моңа авылдагы кайберәүләр көнләшкән, бабайга кырын караучылар саны арткан. Аның руслар даирәсендәге танышлары белән даими аралашуын кайбер куштаннар бик ошатып бетермәгән. Җитешле, мул тормышта яшәгәч, кулак дип йөртүчеләр дә булган.

Илдә колхозлар төзү чоры башлангач, авылда яшәүчеләрне, мәҗбүриләп, күмәк хуҗалыкларга кертү киң җәелә. Карышып маташучылар белән сөйләшеп тә тормыйлар, хәллерәк саналган кешеләрнең бөтен мал-мөлкәтен тартып алалар, үзләрен исә хөкемгә тарталар. Бабай белән дә озак сөйләшеп тормаганнар, йорт-җирен таратып, үзен Спас төрмәсенә алып киткәннәр. Нәүбәһар әби картын кызганып, бик кайгырган, йөрәге түзмәгәч, капчыгына ипи белән бәрәңге салып, Спаска чыгып киткән. Бер надзиратель белән сөйләшеп, шуны кемдер аркылы Хәйдәренә тапшырып кайта алган. Нәүбәһар әби, намазга баскан саен иренә саулык теләп, догалар кыла, Ходайга ялварып, ирен азат итүен сорый. Әмма картын алай тиз генә төрмәдән чыгармыйлар шул. Инде нишләргә? Башка чара калмагач, Хәйдәр бабайның русчаны аз-маз белгән Садыйк атлы улы Мәскәүгә Сталин янына дип чыгып китә. Ни хикмәт, егет юлбашчы белән очраша. Ничек аны Кремльгә уздырганнар – монысы билгесез. Үз кулы белән язган хатын калтырый-калтырый илбашына укып күрсәткән, безнең әти рус-япон сугышыннан Георгий тәресе тагып кайтты, дип аңлатып биргән. Шунысына ис китәрлек: авыл малаен Сталин кызганган булса кирәк, озакламый Хәйдәрне Спас төрмәсеннән азат итәләр. Аны әле авылга кадәр ат белән кайтарып та куйганнар. Авыл куштаннары, ялагайлар бу хәлгә нык көенгән, хәтта бабайдан бераз шүрләп тә йөргәннәр.

Минем бабай алтын куллы кеше иде, нәрсәгә тотынса, шуны булдырды. Төрмәдән кайткач, колхозга кирәк-ярак ташучы булып эшкә урнашкан ул. Ат җигеп, җәй бу кырда эшләгән техникага төрле кирәк-яракны китереп торган, башка йомышларны үтәгән. Бабай вакытын беркайчан бушка уздырмады. Элек бит урманнан агач кисәргә ярамады, тотсалар, эшне гел зурга җибәргәннәр. Ул киселгән имән төбен тамыры белән казып кайта торган иде. Шуны иренмичә кул пычкысы белән ваклап турады һәм кыш буе ягып чыгарлык утын әзерләде. Бабай әле тагын үзлегеннән йорт хайваннарын дәваларга өйрәнгән. Бик күп кешеләрнең терлеген үлемнән алып калды. Аны күрше авылларга да чакыралар иде.

Берсендә күршедәге Сартоновка авылына мине дә ияртеп барды. Авыл башыннан чыгуга бабай, кесәсеннән кульяулыкка төрелгән Георгий тәресен алып, күкрәгенә такты. Рус авылына кергәндә икебезне марҗа әбиләре сырып алды. Ул да түгел: «Эх, наш солдат идет!» – дип, бабайның аркасыннан чәбәкләп, нидер турында сораштыра башладылар. Әмма бабайның алар белән озаклап сөйләшеп торырга вакыты булмады. Без авылның аргы башына төшеп киттек. Бабай берәүләрнең тәкәсен печеп чыкты, икенчеләренең сыерына эчерергә дип кәчтүм кесәсеннән ниндидер дару алып бирде. Әлбәттә инде, эшләрне тәмамлагач, аңа акча биргәннәрен һәм өйгә чакырып сыйлаганнарын хәтерлим.

Кайтканда бабайның күңеле күтәренке иде. Түбәтәен басыбрак киеп, «Порт-Артур»ны көйләп алды: «Порт-Артур дигән калага японнар туп аталар, их-х-х...» Авылга кергәндә Георгий тәресен яңадан кульяулыкка төреп, кесәсенә салды. Кешегә күрсәтергә теләмәгәнгә шулай иткәндер инде. Мөселман кешесенә мондый нәрсәне тагып йөрергә ярамаганлыкны да белә иде ул. Әмма яу кырында кан түгеп алган бит ул аны. Кызганыч, хәзер инде авылда «Порт-Артур» җырын җырлаучылар юк. И бу гомерләр, кемне искә ала башласаң, шул юк...

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ.
Спас районы

Без – детдом балалары

twitter.com

Актаныш районының Такталачык һәм Зәй районының Бигеш авылларындагы балалар йортларында безне үз сабыйларыдай якын иткән тәрбияче-педагогларыбызга олы рәхмәт һәм ихтирам хисләре белән баш иям. Шәхсән мин үзем тумышым белән Мөслим районының Түбән Табын авылыннан, язмыш исә яшьлегемне – энем Рәдиф белән икебезне балалар йорты белән бәйләде. Әтиебез фани дөнья белән бик иртә саубуллашкан. Биш бала белән әнкәй берүзе калган. Иртә таңнан караңгы төшкәнчегә кадәр колхоз эшендә бил бөккән хатынның, өенә кайткач, балаларын назларга хәле калгандыр дисезме? Озакламый әнкәй үзе дә каты зәхмәт эләктерә: үпкәсенә салкын тиюдән сихәтләнә алмады. Шуннан соң безне детдомга илттеләр.

Безне көзен – октябрь аенда алып киттеләр. Әнкәйдән, якыннарыбыздан, туган яктан аерган бу айны һич онытмам, ахры. Гәрчә, нечкәлекләренә кадәр хәтерләрлек яшьтә дә түгел әле без.

Мин – өченче сыйныф укучысы, Рәдиф энекәш – беренчедә. Шулай да гел көтмәгәндә-уйламаганда килеп чыккан аерылышу хәсрәте, өлкәннәр әйтмешли, канга сеңгән.

Мәктәпкә юлыбыз, гадәттәгечә, авыл уртасындагы таш кибет яныннан уза. Кибет тирәсендәге халык: «Болар бүген китәргә тиеш иде бит, илтмиләр микәнни?» – дигән сыман безгә текәлеп-текәлеп карый. Мәктәптә исә барысы да элеккечә иде, дәресләр бер-бер артлы үтә торды, соңгы дәрескә кыңгырау шалтырау алдыннан класска укытучы апа белән мәктәп директоры килеп керделәр. Авылда балалар аз булганлыктан, беренче сыйныф – өченче, икенче сыйныф дүртенчеләр белән бер бүлмәдә укытыла иде. Директор Рәдиф белән миңа, сумкаларыбызны алып, коридорга чыгарга кушты: «Ильяс, Рәдиф, сезгә өегезгә кайтырга кирәк. Иртәгесе көннән сез башка мәктәптә укыячаксыз», – диде.

Өйдә дә безне шаккатырдылар. Ыгы-зыгы. Сөмәя апа мич алдында табагач белән бөтерелә. Күршебез Гөлсинә апа да бездә, районнан Олы апа да кайткан. Табадан чыккан тәмле ис борынны иркәли. Әнкәй тәмам хәлдән тайган, төс-кыяфәте качкан. «Яңа елга хәтле монда укырлар дигәннәр иде бит, бүген үк илтәләрмени?» – ди.

Энем белән мин берни төшенмибез. Аңлатучы да юк. Барысы да ашыга-кабалана. Безгә өстәл янына утырырга кушалар. Кайнар көлчә тоттыралар, чәй ясыйлар. Кыздырылган ит тә өстәлгә куела. Шулай сыйланып утырганда күршебез Гөлфания апа керә дә: «Волга» килде», – диде. Без урам як тәрәзәгә ташланабыз. Әттәгенәсе! Безнең капка төбендә колхоз рәисе машинасы «Волга» тора ич! Машинага чыгып утырдык. «Энекәшләр, уйлаштык та, сезне балалар йортына илтәчәкләр, – диде Олы апа. – Күреп-белеп торасыз, әнкәй нык авырый, түшәктән дә күтәрелә алмый, без килеп йөрербез, сезгә укырга, кеше булырга кирәк». Әнкәй исә буылып-буылып елый: «Башка күрешә алмабыз инде, балакайлар».

Туган авылдан, туганнарыбыздан китеп баруны иләмсез зур капка янына килеп туктагач кына аңладык булса кирәк. Мондый капканы күргәнебез бармыни безнең?! Йортка узабыз, анда безне бер апа каршылады һәм бүлмәләрне күрсәтеп йөрде. Шунда Рәдиф кисәк кенә: «Абый, апа кайда?» – дип сорады. Мин елап җибәрдем, һәм без елый-елый бүлмәдән чыгып йөгердек. Әмма Сөмәя ападан да, «Волга»дан да җилләр искән иде инде. Һич көтмәгәндә менә шулай аерылу йөрәккә яра булып ятты. Гомер буе төзәлмәде ул яра.

Шунда яныбызга ике малай килеп туктады. «Нәмә җылайсыз? – ди берсе. – Әйдәгез, уйнайбыз». Малайлар Рәдифне урап алдылар да, куышлы уйнарга керештеләр, энекәшнең елавын онытып, йөгерүен күргәч, мин дә тынычлана төштем. Көн арты көн үтте, туган якка туганнар янына кайту онытыла башлады. Такталачыктагыча әйтсәк, детдом баласына әйләндек. Минем күңелемне һәрвакыт бер сорау бимазалый: тәрбияче апалар безнең ише ятимнәр күңеленә ничек юл таба алды икән? Түземлекләр, мәрхәмәтле булулары өчен рәхмәт аларга. Тәрбияләделәр дә, белемле дә иттеләр.

Тора-бара һич көтмәгәндә тараттылар Такталачыктагы балалар йортын. Безне Зәй районындагы Бигеш балалар йортына илттеләр. Шулай итеп яңа тормыш башланды, әмма ияләшүләре авыр булды. Кайберәүләр качу ягын да карый башлады, тик качып кая бара алабыз соң? Ятимлек чабудан тарта.

Җәй урталарында бер төркем балаларны Волгоградка экскурсиягә алып киттеләр, мин дә шулар арасында идем, өч атнага якын йөреп кайттык, кайтсам – Рәдиф юк. Аны берничә иптәше белән Баулыдагы интернат-училищега җибәргәннәр икән. Менә шулай итеп абыйлы-энеле туганнар аерылыштык, безнең хәлгә керергә тиешләр иде югыйсә. Без бит игезәкләр кебек яши идек.

Ятимлек ачысы өйрәтте дә, төзәтте дә. Иң мөһиме төшенкелеккә бирелмәдек, авылдашлар, туганнар йөзенә кызыллык китермәдек. Үсә төшкәч, һәркем тормышта үз юлын тапты, безне балалар йортына алып киткәннән соң бик аз гына яшәгән әнкәйнең: «Балакайларым, бәхетле булыгыз», – дип теләве тормышка ашты. Шунысына шатбыз!

Ильяс СӘЛИХҖАН

Эт – дустыбыз, булышчыбыз

Өлкәнәя барган саен күңелемдә яшьлек хатирәләрем яңара, өзек-өзек кенә булса да, шуларны язып үтим әле. Хәзергеге көн дә тынычлык бирми.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр үгезләр.
Кайчан бетәр икән
Бу корона – вируслар, –

дип дәфтәремә язып та куйдым әле. Күршем Мөкәтдәс Шәкүров белән колхоз саламын алып кайтуыбыз әле дә хәтердә. Безне, каян белгәннәр диегез, колхоз рәисе Латыйп белән бригадир Шәрифулла абыйлар каршылады. «Саламны хәзер үк фермага илтегез», – диделәр. Ике тапкыр сөйләшә торган заман түгел, илтеп бушаттык.

Безнең күршедә Шакир бабай Вәлиев яшәде, җәмәгате – Сәрби әби. Шулай кичкырын клубка барырга чыктым. Күршеләребез янәшәсендә Сәрби әбинең хәвефле тавышы ишетелә. «Ни булган икән?» – дисәм, әбине аларның печән өеменә килгән үгез сөзгән. Үгезне ничек алай куып җибәрдем дә әбине күтәреп, өйләренә алып кердем. Медсестра Зәйтүнә апага да хәбәрне җиткердек. Әбине ул аякка бастырды.

Мин 1956–1957 елларда Буада техник училищеда укыдым. Авылга еш кайта идек, кайткан саен эш чыгып кына тора. Бер кайтуымда әти: «Терлекләргә салам алып кайтырга иде», – диде. Бригадирдан сорамыйча салам алып кайтырга ярамаганлыгын беләбез бит инде, Шәрәфулла абый янына киттем. Рөхсәт бирде, җигү өчен үгезгә дә рөхсәте бар иде, әмма үгез дигәнебез, фермада эшләүчеләрнең әйтүенчә, нәсел үгезе булып чыкты. Аны фермага илттем дә, җикмәскә киңәш иттеләр, саламны чанага эт җигеп алып кайттык. Менә шулай эт безнең сакчыбыз да, «эш аты» да булды.

Сәхәветдин РӘХИМОВ.
Буа районы Янтуган авылы

Рәсми документ

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
27 гыйнвар, 2022 ел, № 165/1410 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай районы территориясендә оештырылган № 534, № 565, № 568 сайлау участокларының участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Азнакай районы территориясендә оештырылган № 534, № 565, № 568 сайлау участокларының участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр итә. Тәкъдимнәр һәм документлар кабул итү Татарстан Республикасы Азнакай районы территориаль сайлау комиссиясе тарафыннан 2022 елның 29 гыйнварыннан 2022 елның 18 февраленә кадәр, эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә башкарыла.

Территориаль сайлау комиссиясе (ТИК) атамасы

Территориаль сайлау комиссиясе адресы	
ТР Азнакай районы ТИК	423330, ТР, Азнакай ш., Ленин ур., 22й. (код 8-85592) тел.: 7-26-31

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 29 статьясындагы 1 пункты таләпләренә туры килмәүче затлар, тәгаенләп әйткәндә:

– Россия Федерациясе гражданлыгына ия булмаган затлар, шулай ук чит ил гражданлыгына ия булучы яки Россия Федерациясе гражданинының чит дәүләт территориясендә даими яшәүгә хокукын раслаган башка документка ия булучы Россия Федерациясе гражданнары;

– законлы көченә кергән суд карары нигезендә эшкә сәләтсез, эшкә сәләте чикләнгән дип танылган Россия Федерациясе гражданнары;

– 18 яшькә җитмәгән Россия Федерациясе гражданнары;

– дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары, җирле үзидарә органнары депутатлары;

– сайланылулы вазифаи затлар, шулай ук җирле хакимиятләр башлыклары;

– судьялар (отставкадагы судьялардан тыш), прокурорлар;

– суд карары нигезендә комиссияләр составыннан чыгарылган затлар, шулай ук комиссияне таркату нәтиҗәсендә хәлиткеч тавыш хокукы белән комиссияләр әгъзалары вәкаләтләрен җуйган затлар (комиссия тарафыннан закон бозулар өчен суд тарафыннан үзләренә карата гаепләрнең юклыгы билгеләнгән затлардан тыш) – тиешле суд карары законлы көченә кергәннән соң биш ел эчендә;

– үзләреннән хөкем җәзасы алынмаган затлар, шулай ук сайлаулар һәм референдумнар турында законны бозган өчен суд тәртибендә административ җәзага тартылган затлар – административ җәза билгеләү турында суд карары законлы көченә кергәннән соң бер ел эчендә, кандидатуралары кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертү өчен кирәкле документларга ия булмаган кандидатуралар участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү өчен кирәкле документлар исемлеге

Сәяси партияләр, аларның төбәк бүлекләре, башка структур подразделениеләре өчен

1. Сәяси партиянең яки төбәк бүлегенең, сәяси партиянең башка структур подразделениесенең участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында сәяси партия уставы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

2. Кандидатуралар турында тәкъдим сәяси партиянең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе тарафыннан кертелеп, сәяси партия уставында мондый тәкъдим кертү мөмкинлеге күздә тотылмаганда – сәяси партиянең төбәк бүлегенә, башка структур подразделениесенә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертүгә вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле сәяси партия органының әлеге вәкаләтләрне бирү турында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

Башка иҗтимагый берләшмәләр өчен

1. Иҗтимагый берләшмәнең гамәлдәге уставының нотариуста расланган яки иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле органы раслаган күчермәсе.

2. Иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары яисә төбәк бүлегенең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының яисә иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә иҗтимагый берләшмә исеменнән мондый карар кабул итүгә хокук бирелгән иҗтимагый берләшмәнең башка структур подразделениесе карары.

3. Кандидатуралар турында тәкъдимне иҗтимагый берләшмәнең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе кертеп, иҗтимагый берләшмә уставында 2 пунктта күрсәтелгән мәсьәлә җайга салынмаганда – иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү буенча вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле иҗтимагый берләшмә органының мондый вәкаләтләрне бирү турында карары һәм әлеге вәкаләтләр бирелгән органның участок сайлау комиссияләре составлары резервына тәкъдимнәр кертү турында карары.

Участок комиссияләре составлары резервына кандидатуралар кертү хокукының башка субъектлары өчен

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары, яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышының беркетмәсе. Сайлаучылар җыелышы беркетмәсенең формасы Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 карары белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә № 3 кушымтада китерелгән.

Моннан тыш кандидатуралар кертү хокукының барлык субъектлары тарафыннан түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш.

1. Россия Федерациясе гражданинының хәлиткеч тавыш хокукы белән участок сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләнүенә, участок комиссияләре составлары резервына кертелүгә язмача ризалыгы (Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 карары белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә № 1 кушымта).

2. Россия Федерациясе гражданины паспорты яки кандидатурасы участок комиссияләре составлары резервына кертү өчен тәкъдим ителгән затның гражданлыгы һәм яшәү урыны турында мәгълүматлардан торган Россия Федерациясе гражданины паспортын алыштыручы документы күчермәсе.

Искәрмә. Кирәкле документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына «Сайлау комиссияләре» бүлегендәге «Участок комиссияләре составлары резервы» «2022 елда участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә кертү» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

КОТЛЫЙБЫЗ!

Илебез машина төзү тармагын үстерүдәге казанышлары һәм «КАМАЗ-мастер» командасының «Дакар-2022» халыкара ралли-марафонында җиңү яулавына зур өлеш кертүләре өчен «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы хезмәткәрләре: конструкторлык бүлегенең спорт автомобильләрен сынау һәм модернизацияләү буенча инженеры **Николаев** Эдуард Валентинович, җитештерү цехының сынаучы-машина йөртүчесе **Сотников** Дмитрий Сергеевич, җитештерү цехының сынаучы-машина йөртүчесе **Шибалов** Антон Юрьевич **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

«КАМАЗ-мастер» командасының «Дакар-2022» халыкара ралли-марафонында югары спорт күрсәткечләренә ирешүенә зур өлеш кертүләре һәм илебез машина төзү тармагын үстерүдәге казанышлары өчен «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы хезмәткәрләре: двигательләр эшләү һәм аларны кулдан төгәлләү бүлеге двигательләр эшләү төркеме җитәкчесе **Әхмәдиев** Руслан Хәлил улы, җитештерүне тәэмин итү бүлеге башлыгы **Никитин** Дмитрий Николаевич, конструкторлык бүлеге башлыгы **Яковлев** Евгений Владимирович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

«КАМАЗ-мастер» командасының «Дакар-2022» халыкара ралли-марафонында җиңү яулавына зур өлеш кертүләре һәм илебез машина төзү тармагын үстерүдәге казанышлары өчен «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы хезмәткәрләре: җитештерү цехының автомобильләрне төзекләндерү буенча слесаре **Әхмәтҗанов** Илгиз Рамил улы, җитештерү цехы башлыгы **Погожих** Станислав Васильевич, җитештерү цехының сынаучы-машина йөртүчесе **Рыбаков** Владимир Юрьевич, җитештерү цехының сынаучы-машина йөртүчесе **Татаринов** Иван Александрович; Республикада гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге баш белгече **Гаязова** Фәния Шамил кызы; халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Иске Чаллы табиблык амбулаториясе гомуми практика табибы **Клементьева** Валентина Павловна; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы баш бухгалтеры **Маркухина** Вера Михайловна Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«КАМАЗ-мастер» командасының «Дакар-2022» халыкара ралли-марафонында җиңү яулавына зур өлеш кертүләре өчен «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы хезмәткәрләре: директорның махсус проектлар буенча урынбасары **Вәлиев** Вадим Данис улы, электрика һәм электроника бүлеге башлыгы **Дешкин** Евгений Анатольевич, маркетинг һәм PR-коммуникацияләр бүлеге техник дизайнеры **Еликов** Антон Леонидович, идарәне оештыру бүлегенең персонал буенча менеджеры **Приходько** Елена Геннадьевна; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Россия почтасы» акционерлык җәмгыятенең «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе директоры **Кузнецова** Регина Викторовна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

Тормыш язган хикәятләр

Ташларга җәл, ашарга ярый

Килешәсездер, күп хуҗабикәләр тәм-томның яңарагын, монысы калып торсын әле, башта боларын ашап бетерик дип, элегрәк пешергәнен, сатып алганын ашарга-ашатырга тырыша. Саранлыктан да түгел инде бу, әрәм булмасын, диюбез (авылда әрәм булмый, мал-туар авызына китсә дә, шөкер, муллык, аларга да тәм-том аз эләкми. Шәһәрдә бөтенләй башка вазгыятьтер, бәлки алар аз күләмдә, граммлап кына ала). Икмәк-булкаларның да йомшаграгы чират көтә. Кайчакта артыграк тырышып җибәреп, яңа дигәне дә искереп киткән чаклар була. Табиблар белми генә «свежий» ризык ашказанына зарарлы, димидер, дип юанабыз андый вакытта.

Бер көнне Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә» китабын кулга алган идем. Анда да шуңа охшаш бер истәлеккә тап булдым. «Ялта» дигән бүлектә ул Хәмит Ярми сөйләгән шундый бер хәлне бик кызык итеп укучыга җиткерә. Ялтадан поезд белән Мәскәү аша кайтырга тиешле Хәмит ага күчтәнәчкә бер кәрзин бик яхшы виноград ала. Вагонга керүгә, ачып караса, тегенең бер тәлгәше бозыла башлаган. Әрәм була бит дип уйлап, ул әлеге виноградны ашап куя. Иртән торгач караса, тагын бер сабак бозыла башлаган. Анысын да ашый Хәмит Ярми. Шулай итеп, бозыла башлаганнарын ашый-ашый, ул Мәскәүгә җиткәнче кәрзиннең яртысын бушата. Мәскәүдә әйберләрен саклау камерасына куя да көн буе шәһәрдә йөри. Билгеле, Казан поездына кереп утыруга, тагын теге кәрзинне ачып карый… Тагын берничә тәлгәшнең төсе киткән… һәм тагын, тагын… «Мин кәрзин төбендәге бозылган соңгы тәлгәшне ашаганда, поезд Аракчиноны чыгып килә иде инде. Казанга килеп төшкәч, уйлап куйдым: соң бит, юлга чыгуга тегенең гел тазасын гына ашаган булсам?» – ди ул. Юл буе әйбәт виноград ашап кайткан булыр идем, дип уфтана…

Без дә бит шулай: нәкъ Ярми кебек, җиләк-җимеш, яшелчәнең иң элек бозыла башлаганнарына үреләбез…

Сыер күргән юк, диярсең

Моннан берничә ел элек авылдагы үзгәртеп корылган фермага чит илдән таналар кайтардылар. Зур фурага төяп. Аллы-артлы ГАИ машиналары саклавында. Бигрәк тә шушы саклау-озату дигәннәре кызык тоелды да инде безгә. Сыер бит инде ул! Әллә нинди кыйммәтле товар төягәннәр, диярсең… Дөрес, бу таналарның безнең сыерлар янында алтын бәясе булуын соңрак белдек үзе. Әмма ул чакта күпләр әлеге таналарны күреп калырга да шул сәбәпле чыкты дип беләм. Нинди икән алар?! Полиция сакларлык булгач!

Ферма авылның түбән башында урнашкан. Урамы таррак. Шуңа күп вакыт зур фураларга малны безнең очка кадәр кечкенә техника белән ташып төйиләр иде. Бу юлы алай итмәделәр. Авыл урамы буйлап куып төшкәндә, бәлки имгәнерләр дип уйлаганнардыр. Зур фура авыл урамы буйлап, ярты километрлап арты белән чигенеп төште, бары ферма чатына җиткәч кенә малларны машинадан төшерделәр, диделәр. Шушы хәлне күрүчеләрдән сорагач: «Әй, искитәрлек бер әйберләре юк, кечкенә генә, ябык кына маллар», – дигәннәр иде. Хәзер әнә шулар күрше Салавычтагы фермада әллә икенче, әллә өченче тапкыр бозаулап, сөткә кинәндерә.

Көчең бетсә…

Гомергә эт асрамасак та, балалар кечкенә чакта бик өзгәләнеп сорагач, эт алган идек. Кечкенә генә булып үсә торган дисәләр дә, ул шактый зур үсте. Кыяфәте куркыныч булса да, шөкер, холкы андый түгел. Кечкенә песи балалары да, оясына кереп-чыгып, азыгыннан сыйланып йөри. Элегрәк без янына килүгә, оя өстенә сикереп менә, исәнме, дисәң, аягын бирә иде. Еллар үтте, инде ул да шактый картайды. Йөгереп килеп, гадәттәгечә, оя өстенә менмәкче була, көче җитми, менә алмый… Мескен кыяфәттә борылып китә. Тагын килеп карый – гәүдәсен күтәрә алмый… Оя кырына чыгып утырганда да, элеккечә матур төз итеп утырмый инде, бөкресе чыккан, колаклары шәлперәеп төшкән… Нәкъ өлкән кеше кебек. Дөрес, чит-ят кеше кергәндә әле гайрәтләнеп, өреп ала. Әмма инде һәр хәрәкәте салмак, ашавы да ташка үлчим генә.

Картаю дигәннән, бер бик үзенчәлекле, кызыклы мәчебез бар иде. Иде дип… Ул әле дә исән. Әмма аның да яше бара. Мәчеләр бит гадәттә иркә була, ә ул нигәдер сыпырганны, иркәләгәнне яратмый, бары тик баш түбәсен генә сыпырырга рөхсәт бирә иде. Сыртына кагылсаң, беттең, кычкыра-кычкыра, җан көченә китереп суга, әле тагын да сыпырам дип кул сузсаң, тырнакларын батырып, тиреңне ертып төшерергә дә күп сорамый. Ачуы чыккан андый чакларда юлында очраган яшьрәк песиләргә дә эләгә иде. Моңарчы ничектер игътибар итмәгәнмен (мәчеләр күбрәк шул), шул мәчебез ашарга килгәч, яшьрәкләр, үз алдындагы ризыкларын калдырып, иң элек аның алдындагысын ашый икән. Менә, мин әйтәм, көче беткәнен сизгән болар… Тәмлерәк әйберләр биргәндә, саклап ашатам хәзер.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

РӨСТӘМ УСМАНОВ:

«ГАЗ КЕРТҮ ҮТЕНЕЧЕ БЕЛӘН КИЛГӘН БЕР КЕШЕНЕ ДӘ КИРЕ БОРМАЯЧАКБЫЗ»

Татарстанда киләсе өч ел эчендә 1,2 мең километрдан артык газ торбасы сузылачак һәм унсигез меңнән артык йорт газ челтәренә тоташачак. Газ челтәрләрен төзекләндерү эше дә дәвам итәчәк. Су астындагы газ торбаларын яңарту да читтә калмаячак.

«Газпром трансгаз Казан» оешмасы генераль директоры Рөстәм УСМАНОВ белән 2021 елда эшләнгән эшләр һәм алдагы планнар хакында әңгәмә кордык.

:: Рөстәм Ринатович, узып киткән ел нинди нәтиҗәләр белән истә калды?

– Иң зур нәтиҗәбез – коллективның исән-сау булуы. Бездә эшләүчеләрнең 96 проценты вакцина ясатты һәм шуның белән үзләрен һәм якыннарын коронавирустан саклап кала алды. Безнең хезмәткәрләр гел халык арасында, фатирларга кереп йөриләр бит. Әнә шуңа да вируска бирешмәүләрен зур эш дип саныйм. Тагын шунысы сөендерә: коллективта кешеләрнең хезмәт куркынычсызлыгына бәйле мөнәсәбәте үзгәрде. Алар үзләрен сакларга өйрәнде. Кулына телефон тотып барган кеше юеш идәндә дә таеп егылырга мөмкин. Төп максатыбыз– хезмәткәрләр эштәге куркынычсызлык кагыйдәләрен белергә тиеш. Компьютерларын кабызганда да хезмәткәрләр аны эшләтеп җибәрер өчен берничә сорауга җавап бирә. Алар дөрес булмаса, компьютер кабынмый тора. Кеше өенә, якыннары янына исән-сау кайтып керергә тиеш. Шуңа да сак булырга кирәк. Мин һәрчак үземнән башлыйм. Баскычтан төшкәндә дә тотынгычларга тотынам. Ел нәтиҗәләренә күз салсак, бездә йөртүче гаебе белән бер юл һәлакәте һәм 2 кешенең биеклектән егылып төшү очрагы теркәлде.

Башкарган эшләргә тукталсак, узган ел Миңнебай – Казан магистралендә, газ бүлеп җибәрү станцияләрендә реконструкция эшләре башкарылды. Ел дәвамында төзекләндерәсе барлык эшләр 100 процентка үтәлде. Бу эшкә акча кызганмыйбыз. Күпме кирәк, шуның кадәр тотыла. Узган ел исә капиталь төзекләндерүгә 2 млрд сум акча сарыф ителде. Максатыбыз – һәр өйгә «зәңгәр ягулык» барып җитсен. Бер генә кеше дә газсыз утырмасын! Ел саен оешма Россиянең үзәгендәге төбәкләргә, якын һәм ерак чит илләргә 240 млрд кубометрдан артык газ юллый. Шуның 18 млрд кубометры Татарстанга һәм күрше төбәкләрдәге кайбер районнарга җибәрелә. Республикада 1 миллион 600 абонентны газ белән тәэмин итәбез. Газга елдан-ел ихтыяҗ арта. Узган ел пандемия вакытында бурычлыларны газдан өзәргә ярамаса да, без әҗәтләрне 9,9 процентка киметә алдык.

:: Россия Президенты Владимир Путин Федераль Җыенга еллык Юлламасында 2021–2023 елларда илдә масштаблы газлаштыру программасын тормышка ашырырга күрсәтмә бирде. Бу юнәлештә эшләр башландымы әле?

– Без гариза язган кешеләрнең өй участогына кадәр газ торбасын бушлай тоташтырабыз. Инде безгә 18 меңнән артык гариза килде. Бу эш ике елга исәпләнгән. Әмма без аны әле киләчәктә дә дәвам итәр дип уйлыйбыз. Газлаштыру программасына эләгү өчен кешенең җиргә рәсми рәвештә хокуклы булуы һәм газны өй җылыту һәм ризык әзерләү өчен кертүе мөһим. Газлаштыру өчен гаризаны безгә төрле ысуллар белән юлларга мөмкин. Гаризаны кәгазьдә тутырып, горгаз, райгаз оешмаларына тапшырырга да, «Дәүләт хезмәтләре» порталында да теркәргә мөмкин. Гаризада паспорт, СНИЛС мәгълүматларын, телефон номерын күрсәтергә, йортка һәм җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның күчермәсен кушымта итеп бирергә кирәк. Тагын шунысы да бар: газ кертү үтенече белән килгән бер генә кешене дә кире бормаячакбыз. Без моны ничек булса да, башкарырга тиеш. Әйтик, техник сәбәпләр аркасында ул җиргә торбаларны сузып булмый, бу урында махсус казырга, ниндидер комачау иткән биналарны күчерергә кирәк, ди. Бу очракта, без газ кертүне тиз арада башкара алмаячагыбызны аңлатып, әмма графикка кертеп, әлеге кешегә кайчан эшләячәгебезне әйтеп җибәрергә тиеш. Газ керткәндәге чыгымнарны каплар өчен 4 млрд сум акча тотылачак. Әмма кабатлап әйтәм: газ бары тик өй участогына кадәр генә сузыла. Халыкка газны капка төбеннән өйгә үткәрү өчен үзе түлисе булачак. Кайбер эшләр башланды инде. Республиканың һәр районыннан гаризалар килә. Әмма Тукай районында яшәүчеләрдән мөрәҗәгатьләр күбрәк кабул ителде. Биредә күпбалалы гаиләләргә бирелгән участокларда төзелгән йортларга газ тоташтырырга кирәк. Һәр районда подрядчы оешмаларны конкурс аша сайлап алдык. Алар эшли башлады.

:: «Газпром трансгаз Казан» оешмасы заман белән бергә атлый. Яңа технологияләр буенча эшлисез. Моның өчен фәнни яктан да әзер булырга кирәк бит.

– Узган ел фән өлкәсендә күп кенә уңышларга ирештек. Газны сакчыл тотарга өйрәндек. Махсус технологияләр буенча бер елда 50 миллион кубометр газны экономияләдек. Бу – Казанда яшәүче халыкны бик каты суыкларда 3 тәүлек буе газ белән тәэмин итеп була дигән сүз. Әмма башкарасы эшләр күп әле. Безгә Иннополис фәнни үзәге белгечләре ярдәмгә килә. Алга куелган максатыбыз – су астындагы газ челтәрләренең торышын ачыклау. Белгечләр бу өлкәдә эшли. Пилотсыз аппаратлар белән эшләргә җыенабыз. Бу безгә газ чыгып яткан җирләрне ачыклау, куркыныч очракларны булдырмый калу өчен кирәк. Шулай ук цифрлаштыру буенча да башкарасы эшләр күп. Документлар әйләнеше өчен бердәм портал булдырырга кирәк. Ни генә эшләсәк тә, сыйфат беренче урында тора. Үзебезнең оешмадагы «йомшак» урыннарны беләбез. Шуңа да әле өйрәнәсе эшләр күп.

:: Кадрлар мәсьәләсе ничек тора?

– Үзебезнең оешмага җәлеп итәр өчен мәктәпләрдә махсус «Газпром» класслары бар. Шул балаларны юллама буенча укырга кертәбез. Алар бу очракта оешмада эшләргә тиеш була. КХТИ тәмамлаган белгечләрне дә эшкә алабыз. Әмма хәзер яшьләрне оешмада тоту авыр. Аларга тәҗрибә булмаган килеш, күп акча кирәк. Карьера үсеше турында бик уйламыйлар. Бездә исә хезмәт хакы уртача алганда 55,2 мең сумны тәшкил итә. Хәзер бит төрле логистик оешмалар бар. Алар бернинди тәҗрибәсез, беренче айда ук 60 мең сум акча вәгъдә итә. Яшьләргә шул кирәк. Аларны социаль пакет белән кызыксындырып булмый. Кадрлар кытлыгы булса да, күпчелек хезмәткәрләр оешмага рәхмәтле. Династияләре белән эшләүчеләр күп. Үзебез дә хезмәткәрләргә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз. Күпбалалы гаиләләрне, коронавирус белән авыручыларны игътибарсыз калдырмадык. Ярдәм итү өчен узган ел 1 млрд сум акча тотылды.

:: Сез спортка да зур игътибар бирәсез дип беләбез…

– Спорт – яшәү рәвешебез булырга тиеш. Безнең балалар волейбол клубы бар. Хезмәткәрләр футбол да, хоккей да уйный. Актив тормыш алып баралар икән, моның өчен акча да, игътибар да кызганмыйбыз. Фитнес клубларына йөрү өчен абонементлар да сорыйлар. Ул теләкләренә дә каршы килмибез. Киләчәктә әле берничә команда арасында хоккей ярышы да уздырырга ниятләп торабыз.

:: 2022 елга нинди өметләр баглыйсыз?

– Алдагы еллар җиңел булмас дип уйлыйм. Газга ихтыяҗ елдан-ел арта. Әмма кайчан да булса «зәңгәр ягулык» та бетәчәк. Илдәге хәлләрне уйласаң, һәр тармакта кыенлыклар бар. Әмма җиң сызганып эшләргә кирәк. Бар тик җиренә җиткереп эшләгәндә генә нәтиҗәләргә ирешеп була.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАНАДАГА ЯРДӘМ

Спорт

Киләсе атна ахырында Пекинда Кышкы Олимпия Уеннары башлана. Билгеле булганча, җыелма командага Татарстаннан да 8 спортчы чакырылды. Алардан тыш, Кытай башкаласына «Ак барс»тан тагын 4 чит ил хоккейчысы юл тота. Алар АКШ һәм Канада командалары составында чыгыш ясаячак.

Океанның теге ягындагы НХЛ түрәләре үзләрендә уйнаучы хоккейчыларны Олимпиадага җибәрмәскә карар кылгач, КХЛдагы егетләргә Пекинга юл ачылды. Дөресен әйткәндә, Казаннан капкачы Тимур Билалов белән һөҗүмче Дмитрий Воронковның да Россия җыелма командасына эләгү ихтималы зур түгел иде. Бездә чыгыш ясаган чит ил хоккейчылары белән дә шул ук хәл. Әмма коронавирус спорт дөньясының да астын өскә китерә. Моңарчы бер мәртәбә дә җыелма командага чакырылмаган егетләр 4 елга бер мәртәбә уздырыла торган зур турнирда үз илләренең данын яклаячак.

АКШ җыелма командасына «Ак барс»тан Стивен Кэмпфер чакырылды. Моңа кадәр аның төп җыелма команда составында уйнаганы булмаган. Дөрес, 2005 елда 18 яше тулмаган уенчылар арасында Глинка/Гретцки Кубогында чыгыш ясаган. Кэмпфер «Ак барс»та беренче сезонын уздыра. 46 очрашуда 30 очко туплап, Казан командасының иң нәтиҗәле сакчысы булып танылды.

Канада җыелма командасына чакырылган Джордан Уил да «Ак барс»та беренче елын уйный һәм 30 очко белән «Ак барс»ның иң нәтиҗәле һөҗүмчеләреннән санала. Ул да заманында Канада данын юниорлар арасында узган турнирда гына яклаган. Уилдан тыш, бу ил җыелма командасы составына Марк Барберио белән Джейсон Демерс та керде. Барберионың да төп җыелма командага тәүге мәртәбә чакырылуы, Демерс исә 2017 елгы дөнья чемпионатында 10 очрашуда чыгыш ясаган булган.

ak-bars.ru

Хоккейны игътибар белән күзәтеп бармаган тамашачы Барберио белән Демерсны белеп бетермәскә дә мөмкин. Алар «Ак барс»ка әле декабрь аенда гына килеп кушылды һәм Казан командасы белән 5–6 матчта гына бозга чыкты. НХЛда 272 матчта чыгыш ясаган Барберио Казанга килгәнче Швейцариядәге «Лозанна»да уйнады. Демерсның тәҗрибәсе зуррак: НХЛда ул 699 очрашуда чыгыш ясаган. «Ак барс» аны Мәскәүгә Канада җыелма командасы белән Беренче канал Кубогына килгән җиреннән алып калды.

Шулай итеп, «Ак барс» Россия генә түгел, Канада җыелма командасына да уенчылар әзерләде булып чыга. Иң кызыгы: киләчәктә ни көтәсе дә билгесез. Чөнки КХЛда сезон туктап калды һәм калган матчларның булу-булмавы әле дә хәл ителмәгән.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7043 данә
Гомуми тираж – 18156 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 213

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+